| | |
|---|---|
| **Исполнительный комитет Матакского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Башкарма комитеты** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

Матак авылы

**22 октябрь 2018 ел** **№ 20**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә Чүпрәле муниципаль районының Матак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» 2017 елның 13 мартындагы 1 номерлы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 1 нче кушымтада:**

19 пунктның 2 пунктчасында «ике айдан артык аренда түләмәү» сүзләрен «килешү гамәлдә булган чорда аренда түләве (шул исәптән пеня) буенча булган бурыч, шулай ук стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү турында гариза биргән вакытка җир кишәрлегеннән фактта файдалануга түләү буенча бурыч» сүзләренә алмаштырырга;

2). 2 нче кушымтада:

16 пунктның «в» пунктчасында «мөрәҗәгать итүченең мөһере» сүзләрен «гамәлдәге законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан республикасы Чүпрәле районы
Матак авыл җирлеге башлыгы: В.М.Михайлов